# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 11*
*ноябрь*
*(I өлеш)*
*2012*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
2012

ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84$^{1}/_{16}$. Тираж 122 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2012

Эчтәлек

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР


1667. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................4

1668. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................17

1669. «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .......19

1670. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .....25

1671. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................27

1672. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ................31

1673. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................34

1674. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................35

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1667. Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 11 октябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның хокукый җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе гражданнарының (алга таба – гражданнар) квалификацияле түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы территориясендә тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Әлеге Законның максатлары**

Әлеге Законның максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) гражданнарның федераль законнарда һәм әлеге Законда каралган очракларда түләүсез күрсәтелә торган квалификацияле юридик ярдәм (алга таба – түләүсез юридик ярдәм) алу хокукын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырудан;

2) Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасын булдырудан һәм үстерүдән, дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасын үстерүгә булышлык итүдән һәм аңа дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтүдән;

3) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру, аларның законлы мәнфәгатьләрен яклау, социаль якланыш дәрәҗәсен күтәрү өчен шартлар тудырудан, шулай ук аларның гадел хөкемгә ирешүен тәэмин итүдән.

3 статья. **Татарстан Республикасында түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасында түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле мөнәсәбәтләр Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән җайга салына.

4 статья. **Түләүсез юридик ярдәм төрләре**

1. Түләүсез юридик ярдәм түбәндәге төрләрдә күрсәтелә:

1) телдән һәм язма рәвешләрдә хокукый консультацияләр бирү;

2) гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзү;

3) федераль законнарда һәм әлеге Законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда гражданнарның мәнфәгатьләрен чагылдыру.

2. Түләүсез юридик ярдәм законнар белән тыелмаган бүтән төрләрдә дә күрсәтелергә мөмкин.

5 статья. **Гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләрен билгеләү;

2) дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның Татарстан Республикасы территориясендә үзара хезмәттәшлеге тәртибен федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында билгеләү;

3) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләр башкару.

6 статья. **Гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алуын законнар белән җайга салу;

2) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләр башкару.

7 статья. **Гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасының эшләвен, үсүен һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасына ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

2) гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү һәм авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) һәм аның компетенциясен билгеләү;

3) Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасына керүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын, алар ведомствосындагы учреждениеләрне һәм бүтән оешмаларны билгеләү, аларның компетенциясен билгеләү;

4) дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларга һәм бүтән субъектларга хезмәт өчен түләү һәм аларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә тотылган чыгымнарын компенсацияләү күләмен һәм тәртибен билгеләү;

5) гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан кирәкле бюджет ассигнованиеләре күләмен билгеләү, шулай ук Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә шушы чыгымнарны финанслауны тәэмин итү;

6) гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү, дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасының эшләве, үсүе һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасына ярдәм күрсәтү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында һәм Татар-

стан Республикасы законнарында билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне башкару.

8 статья. **Гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнары гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыруның өстәмә гарантияләрен билгеләүче муниципаль хокукый актлар чыгарырга һәм гражданнарга әлеге Законның 4 статьясында каралган барлык түләүсез юридик ярдәм төрләрен күрсәтергә хокуклы.

9 статья. **Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар**

1. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар түбәндәгеләр була:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр;

2) законнар нигезендә бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары.

2. Адвокатлар Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында Федераль законда һәм әлеге Законда каралган тәртиптә катнаша.

10 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары гражданнарга түләүсез юридик ярдәмне үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма хокукый консультацияләр бирү рәвешләрендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтә.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзеп бирү рәвешендә федераль законнарда һәм

Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм гражданның мәнфәгатьләрен судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда чагылдыра.

11 статья. **Адвокатлар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Адвокатлар Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда һәм тәртиптә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.

2. Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы эшчәнлегендә адвокатларның катнашуын оештыру Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы тарафыннан башкарыла.

3. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларга хезмәт өчен түләү һәм аларның мондый ярдәм күрсәтүгә тотылган чыгымнарын компенсацияләү күләмен һәм тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

12 статья. **Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнарның категорияләре һәм мондый ярдәмне күрсәтү очраклары**

1. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында әлеге Законның 4 статьясында каралган барлык түләүсез юридик ярдәм төрләрен алу хокукына гражданнарның түбәндәге категорияләре ия була:

1) гаиләләренең уртача җан башына кереме Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гражданнар йә керемнәре яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган ялгыз яшәүче гражданнар (алга таба – аз керемле гражданнар);

2) I һәм II төркем инвалидлар;

3) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары;

4) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, шулай ук, мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга

бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;

5) «Олы яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү турында» 1995 елның 2 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә түләүсез юридик ярдәмгә хокукы булган гражданнар;

6) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләрендә тотылучы балигъ булмаганнар һәм иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтүче балигъ булмаганнар, шулай ук, мондый балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча (җинаятькә кагылышлы суд эшләрендә юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрдән тыш) түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;

7) «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокукларының гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә түләүсез юридик ярдәмгә хокукы булган гражданнар;

8) суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган гражданнар, шулай ук, мондый гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре;

9) дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукы федераль законнар һәм әлеге Закон нигезендә бирелгән гражданнар.

2. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатлар дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнарга түбәндәге очракларда телдән һәм язма рәвешләрдә хокукый консультацияләр бирә һәм алар өчен гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзи:

1) күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләр төзү, аларны үзгәртү, өзү, гамәлгә яраксыз дип тану, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә кую (фатир, торак йорт яисә аларның өлешләре гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган очракта);

2) торак урынына хокукны тану, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирелү, торак урынына социаль наем шартнамәсен өзү һәм туктату, торак урыныннан чыгарылу (фа-

тир, торак йорт яисә аларның өлешләре гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган очракта);

3) җир кишәрлегенә милекчелек хокукын, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукын, шулай ук җир кишәрлеген гомерлеккә мирас итеп биләү хокукын тану һәм саклап калу (бәхәсле җир кишәрлегендә яисә аның бер өлешендә гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган торак йорт яисә аның бер өлеше урнашкан очракта);

4) кулланучылар хокукларын яклау (коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлешендә);

5) хезмәт шартнамәсен төзүдән эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән гарантияләрне бозарлык итеп баш тартуы, эш урынына кире кайтарылу, хезмәт хакын түләттерү, шул исәптән ихтыярсыздан эшкә чыкмаган вакыт өчен, эш бирүченең хокукка каршы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында китерелгән мораль зыянны компенсацияләү;

6) гражданны эшсез дип тану һәм эшсезлек буенча пособие билгеләү;

7) туендыручысының хезмәт эшчәнлегенә бәйле рәвештә вафат булуы, имгәнүе яисә сәламәтлегенә башкача зарар килү аркасында китерелгән зыянны түләттерү;

8) социаль ярдәм чаралары бирү, аз керемле гражданнарга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү, торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидияләр бирү;

9) картлык буенча хезмәт пенсияләре, инвалидлык буенча һәм туендыручысыз калган очрак буенча пенсияләр, вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек, йөклелек һәм бала тудыру, эшсезлек буенча, хезмәттә имгәнүгә яисә һөнәри авыруга бәйле пособиеләр, бала тугач бер мәртәбә бирелә торган пособие, бала карау буенча айлык пособие, мәет җирләүгә социаль пособие билгеләү, аларны яңадан исәпләү һәм түләттерү;

10) ата (ана) булуны билгеләү һәм дәгъвалау, алиментлар түләттерү;

11) сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнарны реабилитацияләү;

12) хокукка сәләтлелекне чикләү;

13) психиатрия ярдәме күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуларга карата шикаять белдерү;

14) инвалидларга медик-социаль экспертиза үткәрү һәм аларны реабилитацияләү;

15) дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларның актларына судтан тыш тәртиптә шикаять белдерү.

3. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатлар судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнар мәнфәгатьләрен чагылдыралар, әгәр алар:

1) судларда түбәндәгеләр турында эшләр каралганда дәгъвачылар һәм җавап бирүчеләр булсалар:

а) күчемсез мөлкәткә алыш-бирешләрне өзү, гамәлгә яраксыз дип тану, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм алар белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу һәм мондый хокукларны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту (фатир, торак йорт яисә аларның өлешләре гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган очракта);

б) торак урынына хокукны тану, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирелү, торак урынына социаль наем шартнамәсен өзү һәм туктату, торак урыныннан чыгарылу (фатир, торак йорт яисә аларның өлешләре гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган очракта);

в) җир кишәрлегенә милекчелек хокукын, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукын, шулай ук җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукын тану һәм саклап калу (бәхәсле җир кишәрлегендә яисә аның бер өлешендә гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган торак йорт яисә аның өлеше урнашкан очракта);

2) судларда түбәндәгеләр турында эшләр каралганда дәгъвачылар (мөрәҗәгать итүчеләр) булсалар:

а) алиментлар түләттерү;

б) туендыручысының хезмәт эшчәнлегенә бәйле рәвештә вафат булуы, имгәнүе яисә сәламәтлегенә башкача зарар килү аркасында китерелгән зыянны түләттерү;

3) үзләрен хокукка сәләтсез дип тану турында гариза судта карала торган гражданнар булсалар;

4) сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнар булсалар – реабилитацияләүгә бәйле мәсьәләләр буенча;

5) психиатрия стационарына мәҗбүри салу турында яисә психиатрия стационарында мәҗбүри яткыру срогын озайту турындагы эшләре судларда карала торган гражданнар булсалар.

13 статья. **Татарстан Республикасында гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алуы өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тапшыру тәртибе**

1. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу өчен гражданнар түбәндәге документларны тапшыралар:

1) кирәкле түләүсез юридик ярдәм төре һәм аны күрсәтү нигезе күрсәтелгән килеш, вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган рәвеш буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында гариза;

2) паспорт яисә гражданның шәхесен таныклый торган башка документ;

3) түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнар категорияләренең берәрсенә кертелүне раслый торган документ;

4) әлеге Законның 12 статьясындагы 2 өлешендә каралган очракларда гражданнарның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы таләпләрен нигезли торган документлар.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Әлеге статьяда каралган документлар, әгәр гражданның түләүсез юридик ярдәм алырга шәхсән үзе мөрәҗәгать итү мөмкинлеге булмаса, түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия граждан үтенече буенча башка зат тарафыннан да тапшырылырга мөмкин. Бу очракта гражданның вәкиле, әлеге статьяда күрсәтелгән документлардан тыш, шәхесен раслый торган документ, ышанычнамә яисә законлы вәкил хокукын раслый торган документ тапшыра.

4. Түбәндәге очракларда документларны кабул итүдән баш тартыла:

1) түләүсез юридик ярдәм турында гариза белән тиешсез зат мөрәҗәгать иткән булса;

2) әлеге статьяның 1 өлешендә каралган барлык документлар да тапшырылмаган булса.

5. Документларны кабул итүдән баш тартуга карата вәкаләтле органга яисә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

14 статья. **Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Әлеге Законның 12 статьясындагы 2 өлешендә каралган очракларда дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларын-

да түләүсез юридик ярдәм түбәндәге ярдәмне сорап мөрәҗәгать иткән гражданга күрсәтелә:

1) хокукый характердагы мәсьәлә буенча;

2) бер үк яклар арасындагы бәхәс буенча, бер үк әйбер турында һәм бер үк нигезләр буенча кабул ителеп закон көченә кергән суд карары белән элек хәл ителмәгән мәсьәлә буенча:

а) суд карары (хөкеме) белән;

б) дәгъва белдерүченең дәгъваны кире кагу белән килешүенә бәйле рәвештә эш алып баруны туктату турындагы суд билгеләмәсе белән;

в) җәмәгать килешүен раслауга бәйле рәвештә эш алып баруны туктату турындагы суд билгеләмәсе белән;

3) арадашчы судның бер үк яклар арасындагы бәхәс буенча, бер үк әйбер турында һәм бер үк нигезләр буенча яклар өчен мәҗбүри үтәлергә тиешле кабул ителгән карары булмаган мәсьәлә буенча, арадашчы суд карарын мәҗбүри үтәүгә карата башкару кәгазен бирүдән суд баш тарткан очраклардан тыш.

2. Әгәр граждан Федераль законда һәм әлеге Законда каралмаган түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында сораса, гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тартыла.

3. Законнар нигезендә түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия булган һәм, түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап, дәүләт органнарына яисә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатка мөрәҗәгать иткән гражданга түбәндәге очракларда дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтелми һәм гариза теркәлгән көннән биш эш көне эчендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең мөмкин булмавы турында бәяләмә бирелә, әгәр граждан:

1) хокукый характерда булмаган мәсьәлә буенча түләүсез юридик ярдәм сорап мөрәҗәгать итсә;

2) тиешле таләпләр кую өчен хокукый нигезләр булмаган килеш, гариза, шикаять, үтенечнамә яисә хокукый характердагы башка документ төзеп бирүне һәм (яисә) судта, дәүләт яисә муниципаль органда, оешмада үз мәнфәгатьләрен чагылдыруны сорап мөрәҗәгать итсә;

3) судка, дәүләт яисә муниципаль органга, оешмага мөрәҗәгать итүгә карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән каршылыклар булган килеш, судка гариза язуны һәм (яисә) судта, дәүләт яисә муниципаль органда, оешмада үз мәнфәгатьләрен чагылдыруны сорап мөрәҗәгать итсә.

4. Вәкаләтле дәүләт органнары һәм дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатлар, әгәр прокурор, шушы

гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап, федераль закон нигезендә судка гариза белән мөрәҗәгать иткән булса, гражданга түләүсез юридик ярдәм күрсәтмиләр.

5. Гражданга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тартуга карата суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

6. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә җибәрелә торган акчаларны тотуны тикшереп тору бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

15 статья. **Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы карарларны кабул итү тәртибе**

1. Әлеге Закон максатларында ашыгыч очракларга табигый бәла-казалар (гарасатлар, янгыннар, су басулар, корылык, боз сугу), эпидемияләр, массакүләм чуалышлар, погромнар, ут төртеп яндырулар, афәтләр, шул исәптән һәлакәтләр, гадәттән тыш һәм хәрби хәл кертү, кичектергесез чаралар күрүне таләп итә торган башка охшаш очраклар кертелә.

2. Вәкаләтле орган авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) төзи.

Комиссия Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм дәүләт идарәсен эшләү һәм гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында бердәй финанс, бюджет, салым һәм валюта сәясәтен үткәрүне тәэмин итүче органы, Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы һәм бүтән дәүләт органнары һәм оешмалар вәкилләреннән тора.

Вәкаләтле орган җитәкчесе комиссиягә җитәкчелек итә.

3. Комиссия турындагы нигезләмә вәкаләтле орган җитәкчесенең карары белән раслана.

4. Сәламәтлегенә, туганнарының (якыннарының) гомеренә һәм сәламәтлегенә зарар китерүгә йә аның мөлкәтенә зыян салуга, туганнарының (якыннарының) мөлкәтенә зыян салуга бәйле рәвештә авыр тормыш хәлендә, шулай ук кичектергесез гамәлләрне таләп итә торган бүтән хәлләрдә калган һәм түләүсез юридик ярдәмгә мохтаҗ гражданның ашыгыч очракта Татарстан

Республикасы дәүләт органнарына мөрәҗәгате буенча гражданга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы йә түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тарту хакындагы карар мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә комиссия тарафыннан кабул ителә.

5. Комиссиянең түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тарту турындагы карарына карата граждан суд тәртибендә шикаять белдерергә мөмкин.

16 статья. **Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар**

1. Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасы ихтыярый башлангычларда корыла.

2. Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар юридик клиникалардан (студентларның консультацияләр бюроларыннан, студентларның юридик бюроларыннан һәм башкалардан) һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм үзәкләреннән гыйбарәт.

3. Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасындагы аерым катнашучыларның оешу тәртибе, вәкаләтләре һәм статусы Федераль закон белән җайга салына.

17 статья. **Халыкка хокукый мәгълүмат җиткерү һәм аны хокукый гыйлемле итү**

1. Халыкка хокукый мәгълүмат җиткерү һәм аны хокукый гыйлемле итү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар Федераль законның 28 статьясындагы 1 өлешендә каралган мәгълүматны гражданнар файдалана алырлык урыннарда, массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга йә гражданнарга бүтән ысул белән җиткерергә тиеш.

2. Җирле үзидарә органнары хокукый мәгълүматны халыкка җиткерүне һәм аны хокукый гыйлемле итүне муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыра ала.

3. Халыкка хокукый мәгълүмат җиткерү һәм аны хокукый гыйлемле итү дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

18 статья. **Татарстан Республикасында түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле гамәлләрне финанслау**

1. Федераль законнар, әлеге Закон һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырылуы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм алар ведомствосындагы учреждениеләргә йөкләнә торган түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле гамәлләрне финанслау Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән башкарыла. Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле чыгымнарны бүтән субъектлар акчалары исәбеннән финанслау тиешле субъектлар тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Законда каралган очракларда гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларның хезмәте өчен түләүгә, аларның мондый ярдәм күрсәтүгә тотылган чыгымнарын компенсацияләүгә бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасының чыгымнар йөкләмәсе булып тора.

3. Җирле үзидарә органнарының гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алу хокукына өстәмә гарантияләр билгеләүгә бәйле чыгымнарын финанслау җирле бюджетларның чыгымнар йөкләмәсе булып тора.

19 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 2 ноябре
№ 73-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1668. Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 11 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12; 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 41 статьяның өченче һәм алтынчы абзацларын үз көчен югалткан дип танырга;

2) $53^4$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) $60^1$ статьяның 2 пунктында «Россия Федерациясе бюджет системасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджет системасы» сүзләренә алмаштырырга;

**2 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясындагы 2 пунктының, 18 статьясындагы 2 пунктының, $53^1$ статьясындагы 2 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12; 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш) гамәлдә булуын 2013 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**3 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 елның 11 декабрендәге № 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктын

(Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 8);

2) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 2 августындагы № 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 30 пунктының дүртенче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш), 2010, № 7 (II өлеш);

3) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 3 октябрендәге № 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш);

4) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләрен куллану тәртибе турында» 2009 елның 3 декабрендәге № 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 12 (I өлеш);

5) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 18 ноябрендәге № 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 13 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 11 (I өлеш);

6) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 30 ноябрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунткчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 11 (II өлеш).

**4 статья**

1. Әлеге Закон, шушы Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан, 3 статьясындагы 1 – 3, 6 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты, 3 статьясындагы 1 – 3, 6 пунктлары 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 2 ноябре
№ 74-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1669. «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 11 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» 2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 6; 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның унынчы абзацында «халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә заказ бирүче һәм пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында пассажирлар йөртүче белән төзелгән шартнамәне имзалаучы» сүзләрен «гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс оештыручы һәм аның нәтиҗәләре буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында пассажирлар йөртүче белән шартнамә төзүче» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:

а) бишенче абзацта «халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә һәм пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга заказ биргәндә» сүзләрен «гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс оештырганда һәм пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда» сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацта «халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) заказын булдыру һәм урнаштыру» сүзләрен «маршрут челтәрен булдыру һәм гомуми файдаланудагы транс-

портта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс үткәрү» сүзләренә алмаштырырга;

3) 8 статьяның өченче абзацында «халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә һәм хәрәкәт составы сатып алуга дәүләт заказын финанслау өчен» сүзләрен «пассажирлар йөртүчеләрнең чыгымнарын әлеге Законда каралган очракларда компенсацияләүгә һәм хәрәкәт составы сатып алуга» сүзләренә алмаштырырга;

4) 9 статьяның 1 өлешендә «халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә муниципаль заказ булдыралар һәм урнаштыралар» сүзләрен «муниципаль маршрут челтәрен булдыралар, гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс оештыралар һәм уздыралар» сүзләренә алмаштырырга;

5) 10 статьяда:

а) 1 өлештә:

өченче абзацта «даими маршрутлар буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә заказ булдыра» сүзләрен «халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфат параметрлары нигезендә маршрут челтәрен булдыра» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә заказлар урнаштыруны» сүзләрен «гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс үткәрүне» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «заказ урнаштыру нәтиҗәләре буенча йөртүчеләр» сүзләрен «конкурс нәтиҗәләре буенча пассажирлар йөртүчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә заказ бирү буенча» сүзләрен «Гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс үткәрү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

6) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне оештыру тәртибе**

1. Гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртү пассажирлар йөртүчеләр тарафыннан, әлеге статьяның 18 өлешендә каралган очраклардан тыш, гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс (алга таба

– конкурс) нәтиҗәләре буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга билгеләнгән тәртиптә төзелгән шартнамә нигезендә, шулай ук шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга шартнамәләр төзелгәндә гамәлгә ашырыла.

2. Конкурс пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң яхшы шартларын тәэмин итәрлек пассажирлар йөртүчеләрне сайлап алу максатында уздырыла һәм халыкның имин һәм сыйфатлы йөртүгә ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен гомуми файдаланудагы транспортта гамәлгә ашырыла торган пассажирлар йөртүне җайга салу ысулы булып тора.

3. Конкурс түбәндәге очракларда үткәрелә:

1) даими йөрү маршруты (маршрутлары) ачылганда;

2) пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга элек төзелгән шартнамәнең гамәлдә булу вакыты чыкканда йә бу шартнамә шартларында каралган нигезләр буенча вакытыннан алда өзелгәндә;

3) даими йөрү маршрутына өстәмә маршрутлар кертелгәндә, әгәр әлеге маршрутта пассажирлар йөртүне берничә пассажирлар йөртүче гамәлгә ашырган булса, шулай ук әгәр гамәлдәге пассажирлар йөртүче яңа маршрут графиклары кертелгәндә шартнамәдә билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тәэмин итәргә сәләтле булмаса.

4. Конкурс предметы, конкурс документларында күрсәтелгән, Россия Федерациясе законнарына һәм әлеге Законга туры килә торган таләпләрне үтәп, даими йөрү маршрутында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга шартнамә төзүдән гыйбарәт.

Конкурс объекты кирәкле параметрлары (маршрутның башы һәм ахыры, хәрәкәт составы саны һәм аны куллану характеристикалары, хәрәкәт итү интерваллары яисә рейслар саны) күрсәтелгән бер яисә берничә маршрутны үз эченә алган лотлардан (лоттан) гыйбарәт.

5. Конкурс үткәрү турында хәбәр заказ бирүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына конкурс үткәреләчәк көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

6. Конкурста пассажирлар йөртүләрне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча автомобиль транспорты өлкәсендә законнар һәм бүтән норматив хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәүче аерым бер пассажирлар йөртүче дә, даими йөрү маршрутында пассажирлар йөртүләрне бергәләп башкару өчен граждан законнарында каралган рәвештә берләшкән пассажирлар йөртүчеләр төркеме дә түбәндәге шартларда катнашырга мөмкин:

1) аларның сигез кешедән артыграк пассажир йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе законнарында каралган лицензиясе булса;

2) алар ябылу (үзгәртеп кору) процессында булмаса;

3) алар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә банкротлар дип танылмаса һәм аларга карата банкротлык процедурасы уздырылмаса;

4) аларның конкурс уздыру датасыннан алда килгән календарь ел өчен теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга яисә бюджеттан тыш дәүләт фондларына мәҗбүри түләүләр буенча соңгы тәмамланган хисап чоры өчен бухгалтерлык хисаплылыгы күрсәткечләре буенча активларның баланс хакының 25 процентыннан арткан күләмдә бурычлары булмаса.

7. Пассажирлар йөртүчеләрне конкурска кертү пассажирлар йөртүгә заказ бирүче тарафыннан башкарыла.

8. Конкурста катнашу хокукына заявкаларны бәяләү һәм конкурста җиңүчене сайлап алу өчен пассажирлар йөртүгә заказ бирүче тарафыннан конкурс комиссиясе төзелә.

9. Муниципальара даими йөрү маршрутында пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашыруга сәләтле пассажирлар йөртүчене билгеләгәндә, конкурс комиссиясе утырышында (конкурс заявкасын караганда) территорияләрендә маршрутның тукталыш пунктлары билгеләнгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкилләре дә катнашырга хокуклы.

10. Транспорт хезмәте күрсәтүнең иң яхшы шартларын тәкъдим иткән пассажирлар йөртүче конкурста җиңүче дип таныла. Конкурс комиссиясе пассажирлар йөртүчеләрне түбәндәге критерийлар буенча сайлап ала:

1) хәрәкәт составына карата куелган, конкурс уздыру турындагы хәбәрнамәдә һәм конкурс документларында бәян ителгән таләпләргә туры килә торган, милекчелек хокукында яисә бүтән законлы нигезләрдә пассажирлар йөртүченеке булган хәрәкәт составы булу;

2) пассажирлар йөртүченең пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашыру буенча эш тәҗрибәсе (шул исәптән шушы маршрутта);

3) пассажирлар йөртүләр өчен тәкъдим ителә торган транспорт чараларының характеристикалары (ничә елдан бирле файдаланылуы, экологик күрсәткечләре, техник структурасы, гражданнарның аерым категорияләре өчен файдалану уңайлылыгы);

4) хәрәкәт составы туктап торырлык, аңа техник хезмәт күрсәтерлек һәм ремонт ясарлык, транспорт чарасын йөртүчеләргә рейслар алдыннан, рейслардан соң медицина тикшерүләре, рейслар алдыннан транспорт чараларының техник торышын тикшерү үткәрерлек урыннар һәм җайланмалар булу;

5) транспорт чараларын йөртүчеләр аркасында һәлакәтлелек торышы һәм конкурста катнашучыларның транспорт дисциплинасы турындагы күрсәткечләргә, шулай ук конкурста катнашучыларның юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе законнары, бүтән норматив хокукый актлар һәм техник нормалар таләпләрен үтәмәүләре турындагы мәгълүматка анализ.

11. Конкурска кертү тәртибе, конкурсларны оештыру һәм уздыру тәртибе һәм шартлары, шулай ук конкурс документлары пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы норматив хокукый актлары һәм җирле үзидарә органнарының үз компетенцияләре нигезендә норматив хокукый актлары белән раслана.

12. Конкурс нәтиҗәләре буенча пассажирлар йөртүче белән даими йөрү маршрутында пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашыруга шартнамә (алга таба – шартнамә) төзелә.

13. Шартнамә пассажирлар йөртүчегә даими йөрү маршрутында әлеге шартнамәдә билгеләнгән, конкурс документларында һәм конкурста катнашу заявкасында күрсәтелгәннәргә туры килә торган шартларда пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукы бирә.

14. Пассажирлар йөртүгә заказ бирүче тарафыннан пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашыруга шартнамәнең типик формалары эшләнә, аларда шулай ук шартнамәне вакытыннан алда өзү шартлары да карала.

15. Конкурс түбәндәге сәбәпләр буенча булмаган дип таныла:

1) конкурста катнашуга заявкалар булмау;

2) конкурста катнашуга бер генә заявка бирелү;

3) законлы көченә кергән суд карары буенча.

16. Конкурста катнашуга бер генә заявка бирелү сәбәпле конкурс булмаган дип танылган очракта, бердәнбер заявка биргән пассажир йөртүче белән әлеге статьяның 10 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килү шарты белән шартнамә төзелә.

17. Шул ук даими йөрү маршрутына кабат конкурс уздыру 60 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә.

18. Вакытлыча эшләү шартларында конкурс уздырмыйча гына шартнамәләр төзү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

1) пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга элек төзелгән шартнамә күрсәтелгән шартнамә шартларында каралган нигезләр буенча вакытыннан алда өзелгән булса – әлеге маршрутка конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнгән пассажирлар йөртүче пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра башлаган датага кадәр, ләкин 60 көннән дә артыгракка түгел;

2) конкурс заявкалар булмау сәбәпле, шулай ук законлы көченә кергән суд карары буенча үтмәгән дип танылса, шул исәптән элек тә әлеге маршрутка хезмәт күрсәткән пассажирлар йөртүченең ризалыгы булмаган очракта – әлеге маршрутка конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнгән пассажирлар йөртүче пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра башлаган датага кадәр, ләкин 60 көннән дә артыгракка түгел.

19. Пассажирлар йөртүгә заказ бирүче пассажирлар йөртүчегә шартнамә белән бергә һәр транспорт чарасы берәмлегенә билгеләнгән үрнәктәге маршрут картасын, маршрутның расланган паспортын һәм хәрәкәт расписаниесен бирә.

20. Маршрутта эшләү хокукына маршрут карталарын исәпкә алу, бирү һәм кире алу тәртибе пассажирлар йөртүгә заказ бирүче тарафыннан билгеләнә.»;

7) 14 статьяда:

а) 1 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 өлештә:

сигезенче абзацта «расланган маршрут карталары, расписаниеләр, кирәкле билет-исәпкә алу документлары һәм норматив хокукый актларда каралган башка документлар белән» сүзләрен «кирәкле рөхсәт документлары комплекты белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«инвалидларга транспорт чараларыннан тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар булдыру максатларында транспорт чараларын махсус җиһазлар һәм җайланмалар белән тәэмин итәргә.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырган вакытта рөхсәт документлары комплекты транспорт чарасын йөртүчедә булырга һәм тикшереп торучы органнарга аларның таләбе буенча күрсәтелергә тиеш.»;

8) түбәндәге эчтәлекле $14^1$ статья өстәргә:

«$14^1$ статья. **Пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда кирәкле рөхсәт документлары исемлеге**

1. Маршрут транспорт чарасын йөртүчедә эш вакытында юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган документлардан тыш түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) әлеге транспорт чарасына билгеләнгән тәртиптәге маршрут картасы;

2) маршрутның расланган паспорты һәм хәвефле участоклары күрсәтелгән схемасы яисә аларның күчермәләре;

3) билет продукциясе (билетлар, багаж квитанцияләре, билет-исәпкә алу документлары).

2. Муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөрткәндә транспорт чарасын йөртүчедә өстәмә рәвештә шулай ук транспорт чарасы хәрәкәт итә торган маршрутта урнашкан автовокзаллар, пассажирлар станцияләре белән шартнамәләрнең күчермәләре дә булырга тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 2 ноябре
№ 75-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1670. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011,

№ 3, № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 21 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 4 пунктта «тәэмин итүне» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) җирлектә яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының бүтән вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;»;

в) 20 пунктта «муниципаль төзелешне» сүзләрен «төзелешне» сүзенә алмаштырырга, «җир контролен гамәлгә ашыру» сүзләрен «муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

2) $15^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) инвалидларның җәмәгать берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның бөтенроссия җәмәгать берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтүгә.»;

3) 16 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында «тәэмин итүне» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

4) $16^1$ статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) инвалидларның җәмәгать берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның бөтенроссия җәмәгать берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтүгә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гамәлләрне башкаруга.»;

5) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 4 пунктта «тәэмин итүне» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) шәһәр округында яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының бүтән вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;»;

в) 26 пунктта «муниципаль төзелешне» сүзләрен «төзелешне» сүзенә алмаштырырга, «җир контролен гамәлгә ашыру» сүзләрен «муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

6) 17[1] статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) инвалидларның җәмәгать берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның бөтенроссия җәмәгать берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтүгә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гамәлләрне башкаруга.».

## 2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «б» пунктчасыннан һәм 6 пунктының «б» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «б» пунктчасы һәм 6 пунктының «б» пунктчасы 2013 елның 27 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 12 ноябре
№ 76-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1671. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы һәм максатлары**

1. Әлеге Закон күпфатирлы йортлар белән идарә итү, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак мөлкәтен тоту, коммуналь хезмәтләр күрсәтү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү өлкәсендә гражданнарның торак хокукларын яклауны, шул исәптән республика дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру юлы белән, тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2. Әлеге Закон Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибен һәм муниципаль торак контролен оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органының муниципаль торак контроле органнары белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ һәм $6^2$ статьялар өстәргә:

«$6^1$ статья. **Татарстан Республикасында муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру максатларында муниципаль берәмлек уставы һәм башка муниципаль хокукый актлар белән:

1) җирле үзидарәнең муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнары, аларның оештыру структурасы, вәкаләтләре, функцияләре һәм эшчәнлек тәртибе билгеләнә;

2) җирле үзидарәнең күрсәтелгән вәкаләтле органнары вазыйфаи затларының (алга таба – муниципаль торак инспекторлары) исемлеге һәм аларның вәкаләтләре раслана;

3) муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентлары кабул ителә.

2. Муниципаль торак контроле «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән рәвешләрдә, нигезләрдә, срокларда һәм даимилектә, план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр оештыруның һәм үткәрүнең Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы $4^1$ һәм $4^2$ өлешләрендә каралган үзенчәлекләрен исәпкә алып, гамәлгә ашырыла.

3. Муниципаль торак инспекторлары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә:

1) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан һәм гражданнардан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны дәлилләнгән язма гарызнамәләр нигезендә соратып алалар;

2) хезмәт таныклыгын һәм муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерү билгеләү турындагы боерыгының (күрсәтмәсенең) күчермәсен күрсәтеп, территорияләргә һәм аларда урнашкан күпфатирлы йортларга, күпфатирлы йортларның гомуми файдалану урыннарына, күпфатирлы йортлардагы торак урыннарга тоткарлыксыз кереп йөриләр, аларны карап тикшереп чыгуны, шулай ук өйрәнүне, сынауны, һәрьяклап тикшерүне, экспертизалауны һәм контроль буенча бүтән гамәлләрне башкаралар.

4. Тикшерүләр үткәргәндә юридик затның, индивидуаль эшкуарның һәм гражданның мәҗбүри таләпләрне бозулары ачыкланган очракта, тикшерү үткәргән муниципаль торак инспекторлары:

1) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең срокларын күрсәтеп, һәм (яисә) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зыян китерүне булдырмый калу чаралары,

шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар уздыру турында күрсәтмәләр бирәләр;

2) ачыкланган хокук бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү, гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү ихтималын булдырмый калу чараларын, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрәләр, шул исәптән:

а) Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органына административ җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозуларга бәйле аның компетенциясендәге материалларны административ хокук бозу турында эш кузгату хакындагы мәсьәләне хәл итү өчен җибәрәләр;

б) мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материалларны җинаятьләр билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату мәсьәләләрен хәл итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрәләр.

$6^2$ статья. **Республика дәүләт торак күзәтчелеге органының муниципаль торак контроле органнары белән хезмәттәшлек итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы һәм муниципаль торак контроле органнары тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә түбәндәге мәсьәләләр буенча хезмәттәшлек итәләр:

1) республика дәүләт торак күзәтчелеген, муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар һәм методик документлар турында мәгълүмат бирү;

2) үткәрелә торган тикшерүләр нәтиҗәләре, тикшерелә торган торак фондының техник торышы, торак өлкәсендәге законнарның үтәлеше турында муниципаль торак контроле органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелегенең вәкаләтле органына мәгълүмат бирү;

3) план буенча уртак тикшерүләр үткәрү максатларын, күләмен, срокларын билгеләү;

4) республика дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру өлешендә законнарны камилләштерү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр әзерләү;

5) муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы белгечләрнең квалификациясен күтәрү;

6) республика дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органының муниципаль торак контроле органнары белән хезмәттәшлек итүе буенча административ регламентлар кабул итү.

2. Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органының һәм муниципаль торак контроле органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрен, шул исәптән план буенча һәм планнан тыш уртак тикшерүләр үткәрү буенча да, җайга салуны гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 23 ноябре
№ 77-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1672. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территори-

риясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасында муниципаль<br>берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына<br>Татарстан Республикасы территориясендә<br>гражданнарның аерым категорияләре өчен<br>җәмәгать транспорты хезмәтләреннән<br>бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген<br>тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт<br>вәкаләтләрен бирү турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару методикасы**

I-муниципаль районы (шәһәр округы) өчен субвенцияләрнең планлаштырыла торган күләме бер тапкыр юл йөрү исәбеннән гомуми файдаланудагы шәһәр транспортында пассажирлар йөртүнең уртача тарифыннан, бер айда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталар) буенча исәпләүгә кабул ителә торган юл йөрүләрнең айлык уртача саныннан, бер айга исәпләгәндә сатылган бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарның) уртача саныннан һәм бердәй айлык социаль юл йөрү билетының һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетының билгеләнгән хакыннан (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарны тутыру хакыннан) чыгып билгеләнә.

Субвенция күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_i = (Т_{ср.} \times П_{ср.} – Ц_в) \times Р_в \times 12 \text{ ай} + (Т_{ср.} \times П_{ср.} – Ц_д) \times Р_д \times 12 \text{ ай},$$

монда:

$С_i$ – i-муниципаль районына (шәһәр округына) бүлеп бирелә торган субвенция күләме;

$Т_{ср.}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) бер тапкыр юл йөрү исәбеннән гомуми файдаланудагы шәһәр транспортында пассажирлар йөртүнең уртача тарифы.

Юл йөрү өчен өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта белән түләгәндә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тарифлар буенча бәяләрне дәүләт җайга салуы өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан 50 тапкыр һәм аннан күбрәк юл йөрүгә озак вакытлы файдаланудагы билетлар белән юл йөрүне түләү өчен билгеләнгән гамәлдәге тарифлардан чыгып исәпләнгән гомуми файдаланудагы шәһәр транспортында пассажирлар йөртүнең уртача тарифы кулланыла;

$П_{ср.}$ – узган ел белешмәләре нигезендә бер айда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты яки балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта) буенча юл йөрүләрнең айлык уртача саны.

І-муниципаль районында (шәһәр округында) юл йөрүләрнең саны автоматлаштырылган рәвештә исәпләп барылганда, өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта буенча юл йөрүләрнең уртача саны юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторларының узган ел белешмәләреннән чыгып алына.

І-муниципаль районында (шәһәр округында) юл йөрүләрнең саны автоматлаштырылган рәвештә исәпләп барылмаганда, бердәй айлык социаль юл йөрү билеты яисә балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты буенча юл йөрүләрнең уртача саны 50 тапкыр юл йөрүгә тигез итеп алына;

$Ц_в$ – бердәй айлык социаль юл йөрү билетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән хакы;

$Ц_д$ – балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән хакы;

$Р_в$ – і-муниципаль районында (шәһәр округында) бер айга исәпләгәндә сатылган бердәй айлык социаль юл йөрү

билетларының (өстәмә транспорт ташламасы булган тутырылган электрон карталарның) уртача саны;

$P_д$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) бер айга исәпләгәндә балалар өчен сатылган бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының (өстәмә транспорт ташламасы булган тутырылган электрон карталарның) уртача саны.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2012 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 24 ноябре
№ 78-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1673. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (I өлеш); 2009, № 6; 2011, № 5, № 11 (I өлеш), «10» санын «50» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм

оешмалар табышына салым буенча чираттагы салым чоры аеның беренче числосыннан иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 29 ноябре
№ 79-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1674. 2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

1. 2013 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 128 328 252,5 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 131 504 075,7 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 3 175 823,2 мең сум итеп.

2. 2014 елга һәм 2015 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2014 елга – 128 596 435,6 мең сум һәм 2015 елга 134 006 682,7 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2014 елга – 130 233 461,1 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны – 5 200 000,0 мең сум, һәм 2015 елга – 135 154 125,8 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 7 000 000,0 мең сум итеп;

3) 2014 елга Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 1 637 025,5 мең сум итеп һәм 2015 елга 1 147 443,1 мең сум итеп.

3. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

**2 статья**

1. 2014 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген – 88 461 060,2 мең сум, шул исәптән дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрнең иң югары чиген 20 344 920,0 мең сум күләмендә билгеләргә.

2. 2015 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген – 89 838 862,2 мең сум, шул исәптән дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрнең иң югары чиген 20 314 248,0 мең сум күләмендә билгеләргә.

3. 2016 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген – 77 753 567,9 мең сум, шул исәптән дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрнең иң югары чиген 7 281 896,0 мең сум күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

2013 елда – 107 057 682,2 мең сум күләмендә;

2014 елда – 102 314 294,2 мең сум күләмендә;

2015 елда – 108 462 359,9 мең сум күләмендә.

5. 2013 елга Татарстан Республикасы эчке дәүләт үзара хисаплашулары программасын, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт үзара хисаплашулары программасын әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында 2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^1$ статьясындагы 2 пункты нигезендә 2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасының бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

1. Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционер җәмгыятьләрнең идарә органнарындагы дәүләт вәкилләре, 2012, 2013 һәм 2014 еллар нәтиҗәләре буенча чиста табышны бүлү һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча акционер җәмгыятьләрнең идарә органнары (директорлар советы, күзәтү советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, акцияләр буенча дивидендларны тәңгәл рәвештә 2013, 2014 һәм 2015 елларның 1 сентябренә кадәр срокта (әгәр җәмгыять уставында башка срок билгеләнмәгән булса) ел йомгаклары буенча чиста табышның кимендә 30 проценты күләмендә акчалата түләү өчен тавыш бирергә тиеш.

2. 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының 2012, 2013 һәм 2014 еллар йомгаклары буенча салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган өлеше чиста табышның 30 проценты күләмендә 2013, 2014 һәм 2015 елларның 1 июленә кадәр тәңгәл рәвештә кертелә дип билгеләргә.

**6 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

**7 статья**

1. 2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүне әлеге Законга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Законга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2013 елга – 19 663 912,0 мең сум, 2014 елга – 18 581

429,1 мең сум һәм 2015 елга 19 157 298,6 мең сум күләмендә расларга.

**8 статья**

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга һәм товарлар җитештерүче (эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче) физик затларга субсидияләр, шулай ук Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^5$ статьясында каралган бюджетара трансфертлар әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

**9 статья**

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында җирлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында муниципаль районнар (шәһәр округлары) бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге статьяда күрсәтелгән бюджетара субсидияләр җирле бюджетларда тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан законнар нигезендә карала.

4. 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында әлеге статьяда каралган җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара субсидияләрне күчерү ай саен тигез өлешләрдә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

**10 статья**

1. 2013 елга җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 1 814,4 мең сум итеп расларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә – 558,7 мең сум күләмендә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә 1 255,7 мең сум күләмендә бирергә.

2. 2014 елга җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр

бирүгә кагылышлы өлешендә 2 545,2 мең сум итеп расларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә – 783,4 мең сум күләмендә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә 1 761,8 мең сум күләмендә бирергә.

3. 2015 елга җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 2 782,4 мең сум итеп расларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә – 856,1 мең сум күләмендә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә 1 926,3 мең сум күләмендә бирергә.

**11 статья**

1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

2013 елга – 11 242 620,1 мең сум күләмендә;

2014 елга – 13 424 475,4 мең сум күләмендә;

2015 елга – 14 866 599,7 мең сум күләмендә.

Әлеге өлештә күрсәтелгән дотацияләрне 2013 елда – 9 932 236,6 мең сум, 2014 елда – 11 016 037,2 мең сум, 2015 елда 12 196 580,0 мең сум күләмендә физик затлар керемнәренә салымнан суммаларның өстәмә нормативлары белән алмаштырырга.

2. 2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне һәм физик затлар керемнәренә салымнан суммаларның шул дотацияләрне алмаштыра торган өстәмә нормативларын әлеге Законга 11 нче кушымта нигезендә расларга.

**12 статья**

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында җирле бюджетларга бирелә торган субсидияләр күләмен 2013 елга – 5 314 465,4 мең сум, 2014 елга – 3 857 872,3 мең сум һәм 2015 елга 3 801 437,8 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

1) муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә һәм аларның бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүгә муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр, әлеге Законга 12 нче кушымта нигезендә бүлеп;

2) төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне; өстәмә белем һәм һәркем өчен мөмкин булган түләүсез мәктәпкәчә белем бирүне оештыруга, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр, әлеге Законга 13 нче кушымта нигезендә бүлеп;

3) күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга һәм гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр 2013 елга – 1 571 673,1 мең сум, 2014 елга – 1 373 131,0 мең сум һәм 2015 елга 1 373 131,0 мең сум күләмендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә бүлеп;

4) «2012 – 2015 елларга «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» озак сроклы максатчан программасын гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр 2013 елга – 50 000,0 мең сум, 2014 елга – 50 000,0 мең сум һәм 2015 елга 50 000,0 мең сум күләмендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә бүлеп.

**13 статья**

Җирле бюджетларга субвенцияләр күләмен 2013 елга – 11 541 756,3 мең сум, 2014 елга – 12 104 697,5 мең сум, 2015 елга 12 650 708,4 мең сум итеп расларга, шул исәптән:

1) җирлекләргә региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 14 нче кушымта нигезендә бүлеп;

2) гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 15 нче кушымта нигезендә бүлеп;

3) сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак дәвалауга мохтаҗ булган балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыру мәгариф учреждениеләрендә,

психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне оештыруга Түбән Кама муниципаль районы бюджетына 2013 елга – 36 376,2 мең сум, 2014 елга – 38 322,9 мең сум, 2015 елга 40 258,8 мең сум күләмендә субвенцияләр;

4) балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 16 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

5) административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 17 нче кушымта нигезендә бүлеп;

6) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 18 нче кушымта нигезендә бүлеп;

7) халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр 2013 елга – 486,3 мең сум, 2014 елга – 512,5 мең сум һәм 2015 елга 538,4 мең сум күләмендә;

8) торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 19 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

9) мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 20 нче кушымта нигезендә бүлеп;

10) мәгариф учреждениеләрен мәгълүмат белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 21 нче кушымта нигезендә бүлеп;

11) архив эше өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 22 нче кушымта нигезендә бүлеп;

12) опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муни-

ципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 23 нче кушымта нигезендә бүлеп;

13) күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 24 нче кушымта нигезендә бүлеп;

14) граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 25 нче кушымта нигезендә бүлеп;

15) хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 26 нчы кушымта нигезендә бүлеп;

16) гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез файдалануны тәэмин итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр 2013 елга – 654 376,2 мең сум, 2014 елга – 654 376,2 мең сум һәм 2015 елга 654 376,2 мең сум күләмендә;

17) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр 2013 елга – 34 920,0 мең сум, 2014 елга – 34 980,0 мең сум һәм 2015 елга 35 040,0 мең сум күләмендә;

18) хайваннарның авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулардан яклау гамәлләрен уздыруны оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округы бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 27 нче кушымта нигезендә бүлеп;

19) йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яисә таралу өчен шартлар булган һәм сакланып кала торган территорияләрдә һәм урыннарда дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация үткәрү чараларын,

лаборатор тикшеренү методларын кулланып уздырыла торган санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны башкаруны оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына субвенцияләр, әлеге Законга 28 нче кушымта нигезендә бүлеп.

**14 статья**

Китапханәләрнең китап фондларын туплауга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бюджетара трансфертлар күләмен 2013 елга – 9 275,0 мең сум, 2014 елга – 9 275,0 мең сум һәм 2015 елга 9 275,0 мең сум күләмендә расларга, әлеге Законга 29 нчы кушымта нигезендә бүлеп.

**15 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен 2013 елга – 7 913 419,0 мең сум, 2014 елга – 8 235 644,4 мең сум, 2015 елга 8 558 139,0 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар күләмен 2013 елга – 8 117 635,6 мең сум, 2014 елга – 8 642 696,2 мең сум, 2015 елга 9 175 266,4 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

1) мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруны өстәмә рәвештә финанс белән тәэмин итүгә 2013 елга – 3 260 258,6 мең сум, 2014 елга – 3 474 606,4 мең сум, 2015 елга 3 691 956,0 мең сум күләмендә;

2) медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә 2013 елга – 65 166,8 мең сум, 2014 елга – 69 440,2 мең сум, 2015 елга 73 771,4 мең сум күләмендә.

3. Әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри

медицина иминияте фонды бюджетына ай саен күчерелә дип билгеләргә.

**16 статья**

Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2013 елга – 10 514 000,0 мең сум, 2014 елга – 10 690 900,0 мең сум, 2015 елга 10 832 600,0 мең сум күләмендә расларга һәм аларны тәңгәл рәвештә 2013, 2014 һәм 2015 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы гамәлләрен тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**17 статья**

2013 елда инвестиция салым кредитларын бирүгә юнәлдерелә торган чараларның иң чик күләмен 100 000,0 мең сум итеп билгеләргә.

**18 статья**

1. 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында җирле бюджетларның кытлыкларын өлешчә каплау, җирле бюджетларны үтәгәндә барлыкка килә торган вакытлыча касса өзеклекләрен каплау өчен, шулай ук җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан элегрәк бирелгән бюджет кредитларын рефинанслау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләргә бюджет кредитлары өч елга кадәр срокка ел саен 500 000,0 мең сум күләмендә бирелә дип билгеләргә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән кредитлардан файдаланган өчен түләүне түбәндәгечә билгеләргә:

1) җирле бюджетларның кытлыкларын өлешчә каплау, җирле бюджетларны үтәгәндә барлыкка килгән вакытлыча касса өзеклекләрен каплау өчен – бюджет кредиты бирү турындагы шартнамәне төзү көненә Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдә булган рефинанслау ставкасының икедән бере күләмендә;

2) Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга элегрәк бирелгән бюджет кредитларын рефинанслауга – бюджет кредиты бирү турындагы шартнамәне төзү көненә Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдә булган рефинанслау ставкасының өчтән икесе күләмендә.

3. Бюджет кредитлары муниципаль берәмлекләргә бюджет кредитларын кире кайтару, тиешле шартнамәләрдә карал-

ган процентларны һәм бүтән түләүләрне башкару буенча үз йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итмичә генә бирелә.

4. Элек бирелгән кредитлар буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләнми калган бурычы булган муниципаль берәмлеккә бюджет кредиты бюджет кредитын каплауның нигезләнгән чыганаклары булмаган очракта һәм барлыкка килгән кытлыкны һәм касса өзеклеген каплау өчен муниципаль берәмлекнең эчке хисаплашуларны җәлеп итү программасына үзгәрешләр кертү мөмкинлеге булганда, шулай ук бюджет законнары таләпләре үтәлмәгәндә бирелә алмый.

5. Бюджет кредиты әлеге Законда каралган бюджет ассигнованиеләре шартларында һәм чикләрендә, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелгән шартнамәгә таянып, Россия Федерациясе Бюджет кодексының һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларының нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә бирелә.

**19 статья**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы законнарында каралган очраклардан тыш, 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең һәм дәүләт учреждениеләрендә эшләүчеләрнең санын, шулай ук аларны тотуга чыгымнарны арттыруга китерерлек карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирле үзидарә органнарына 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләрдә эшләүчеләрнең санын арттыруга китерерлек карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**20 статья**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы бюджетының вакытлыча тотылмый торган чараларын банк депозитларында урнаштырырга хокуклы.

2. Бюджет чараларын банк депозитларында урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

**21 статья**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2013 елда, 2014 һәм 2015 еллар план чорында элек бирелгән бюджет кредитлары буенча бурычны биш елга кадәр срокка реструктуризацияләү турында карарлар кабул итәргә хокуклы.

2. Максатка яраксыз файдаланылган чаралар суммалары, шулай ук кредитлар, суд карары нигезендә эзләтеп алынырга тиешле исәпләнелгән процентлар һәм пенялар буенча бурыч суммалары реструктуризацияләнергә тиеш түгел.

3. Реструктуризацияләү Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелгән килешү нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларының нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**22 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында федераль бюджеттан алына торган бюджетара трансфертларны, әлеге Законга 30 нчы кушымтага таянып, 2013 елда – 10 988 311,2 мең сум, 2014 елда – 7 225 922,2 мең сум һәм 2015 елда 7 091 969,4 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

**23 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**24 статья**

Суд эшчәнлеге турындагы, башкару эшчәнлеге турындагы һәм бөлгенлек (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^2$ статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына таянып, Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләре буенча бурычлыларның бурычын җайга салу шартларын билгели торган, йөкләмәләр үтәүне кичектереп тору, йөкләмәләрне өлешләп үтәү турында,

шулай ук бурычлыларны исәпләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итү юлы белән йөкләмәләре күләмен киметү турында килешү шартнамәләре төзергә хокуклы.

**25 статья**

1. 2013 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр чорга түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 2 (I өлеш), Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән финанслау өлешендә;

2) «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясындагы 1 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11; 2007, № 11; 2008, № 6), Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән финанслау өлешендә.

2. 2013 елның 1 гыйнварыннан 2013 елның 31 декабренә кадәр чорга әлеге Законга 31 нче кушымта нигезендә җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирүне күз алдында тота торган Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә кертергә.

**26 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 30 ноябре
№ 80-ТРЗ

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

1 нче таблица

# 2013 елга
# Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 3 175 823,2 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджет-ларыннан бюджет кредитлары | 2 577 982,2 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджет-ларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредит-лары | 2 577 982,2 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджет-ларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредит-лары алу | 21 144 940,2 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджет-ларыннан Татарстан Респуб-ликасы бюджеты тарафыннан Россия Федерациясе валюта-сында кредитлар алу | 21 144 940,2 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджет-ларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -18 566 958,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджет-ларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын Татарстан Республикасы бюджеты тарафыннан каплау | -18 566 958,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджет чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 565 437,0 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетлар чараларының калган өлешләрен арттыру | -170 380 180,7 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен арттыру | -170 380 180,7 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | -170 380 180,7 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | -170 380 180,7 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетлар чараларының калган өлешләрен киметү | 170 945 617,7 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен киметү | 170 945 617,7 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 170 945 617,7 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 170 945 617,7 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 32 404,0 |
| 01 06 01 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләр һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләре | 20 000,0 |
| 01 06 01 00 00 0000 630 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 20 000,0 |
| 01 06 01 00 02 0000 630 | Татарстан Республикасы милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 20 000,0 |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -20 374 584,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -20 374 584,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 01 06 04 01 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -20 374 584,0 |
| 01 06 04 01 02 0000 810 | Дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәү | -20 374 584,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 20 386 988,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 20 886 988,0 |
| 01 06 05 01 00 0000 600 | Юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 20 278 124,0 |
| 01 06 05 01 02 0000 640 | Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 20 278 124,0 |
| 01 06 05 02 00 0000 600 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 608 864,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 01 06 05 02 02 0000 640 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 608 864,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 500 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -500 000,0 |
| 01 06 05 02 00 0000 500 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -500 000,0 |
| 01 06 05 02 02 0000 540 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -500 000,0 |
| Барлык чыганаклар | | 3 175 823,2 |

2 нче таблица

## 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел |
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 1 637 025,5 | 1 147 443,1 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | 1 408 474,0 | 947 057,7 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары | 1 408 474,0 | 947 057,7 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары алу | 13 853 234,0 | 18 623 497,7 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджеты тарафыннан Россия Федерациясе валютасында кредитлар алу | 13 853 234,0 | 18 623 497,7 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -12 444 760,0 | -17 676 440,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын Татарстан Республикасы бюджеты тарафыннан каплау | -12 444 760,0 | -17 676 440,0 |
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджет чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 219 303,1 | 193 055,6 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетлар чараларының калган өлешләрен арттыру | -163 303 838,0 | -173 451 758,2 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен арттыру | -163 303 838,0 | -173 451 758,2 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | -163 303 838,0 | -173 451 758,2 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Татарстан Респуб-ликасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен арттыру | -163 303 838,0 | -173 451 758,2 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетлар чараларының калган өлешләрен киметү | 163 523 141,1 | 173 644 813,8 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетлар чараларының калган башка өлешләрен киметү | 163 523 141,1 | 173 644 813,8 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетлар акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 163 523 141,1 | 173 644 813,8 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Татарстан Респуб-ликасы бюджеты акчаларының калган башка өлешләрен киметү | 163 523 141,1 | 173 644 813,8 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кыт-лыкларын эчке финанслауның баш-ка чыганаклары | 9 248,4 | 7 329,8 |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -20 344 920,0 | -20 314 248,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Рос-сия Федерациясе валютасында үтәү | -20 344 920,0 | -20 314 248,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 06 04 01 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -20 344 920,0 | -20 314 248,0 |
| 01 06 04 01 02 0000 810 | Дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәү | -20 344 920,0 | -20 314 248,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 20 354 168,4 | 20 321 577,8 |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 20 854 168,4 | 20 821 577,8 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 06 05 01 00 0000 600 | Юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 20 274 968,4 | 20 273 049,8 |
| 01 06 05 01 02 0000 640 | Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 20 274 968,4 | 20 273 049,8 |
| 01 06 05 02 00 0000 600 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 579 200,0 | 548 528,0 |
| 01 06 05 02 02 0000 640 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 579 200,0 | 548 528,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 500 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары бирү | -500 000,0 | -500 000,0 |
| 01 06 05 02 00 0000 500 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -500 000,0 | -500 000,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01 06 05 02 02 0000 540 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -500 000,0 | -500 000,0 |
| Всего источников | | 1 637 025,5 | 1 147 443,1 |

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

1 нче таблица

# 2013 елга Татарстан Республикасының эчке дәүләт үзара хисаплашулары программасы

(мең сумнарда)

| | Суммасы |
|---|---|
| Эчке дәүләт үзара хисаплашулары | |
| җәлеп итү | 21 144 940,2 |
| бурычның төп суммасын каплауга юнәлдерелә торган акчалар күләме | 18 566 958,0 |
| шул исәптән: бюджет кредитлары | |
| җәлеп итү | 21 144 940,2 |
| бурычның төп суммасын каплауга юнәлдерелә торган акчалар күләме | 18 566 958,0 |

2 нче таблица

## 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасының эчке дәүләт үзара хисаплашулары программасы

(мең сумнарда)

| | Суммасы | |
|---|---|---|
| | 2014 ел | 2015 ел |
| Эчке дәүләт үзара хисаплашулары | | |
| җәлеп итү | 13 853 234,0 | 18 623 497,7 |
| бурычның төп суммасын каплауга юнәлдерелә торган акчалар күләме | 12 444 760,0 | 17 676 440,0 |
| шул исәптән:<br>бюджет кредитлары | | |
| җәлеп итү | 13 853 234,0 | 18 623 497,7 |
| бурычның төп суммасын каплауга юнәлдерелә торган акчалар күләме | 12 444 760,0 | 17 676 440,0 |

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

1 нче таблица

## 2013 елга
## Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре

(мең сумнарда)

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Салым һәм салым булмаган керемнәр | 1 00 00000 00 0000 000 | 114 126 449,1 |
| Табышка салымнар, керемнәр | 1 01 00000 00 0000 000 | 74 796 711,0 |
| Оешмалар табышына салым | 1 01 01000 00 0000 110 | 45 000 000,0 |
| Физик затлар керемнәренә салым | 1 01 02000 01 0000 110 | 29 796 711,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) салымнар | 1 03 00000 00 0000 000 | 15 146 000,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган акцизлы товарларга (продукциягә) акцизлар | 1 03 02000 01 0000 110 | 15 146 000,0 |
| Җыелма керемгә салымнар | 1 05 00000 00 0000 000 | 2 846 757,0 |
| Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 01000 00 0000 110 | 2 846 757,0 |
| Мөлкәткә салымнар | 1 06 00000 00 0000 000 | 17 468 016,0 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым | 1 06 02000 02 0000 110 | 15 316 000,0 |
| Транспорт салымы | 1 06 04000 02 0000 110 | 2 150 000,0 |
| Уен бизнесына салым | 1 06 05000 02 0000 110 | 2 016,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен салымнар, җыемнар һәм даими түләүләр | 1 07 00000 00 0000 000 | 43 000,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1 07 01000 01 0000 110 | 43 000,0 |
| Дәүләт пошлинасы | 1 08 00000 00 0000 000 | 152 360,0 |
| Дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук бүтән юридик әһәмиятле гамәлләрне башкарган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 07000 01 0000 110 | 152 360,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 1 11 00000 00 0000 000 | 1 632 430,0 |
| Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләренә туры килә торган табыш яисә Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының яисә муниципаль берәмлекләрнең акцияләре буенча дивидендлар рәвешендәге керемнәр | 1 11 01000 00 0000 120 | 117 000,0 |
| Бюджетлар акчаларын урнаштырудан керемнәр | 1 11 02000 00 0000 120 | 750 000,0 |
| Ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар | 1 11 03000 00 0000 120 | 342 348,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) түләүле файдалануга тапшырган өчен аренда түләве йә башка түләү рәвешендә алына торган керемнәр | 1 11 05000 00 0000 120 | 346 407,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән түләүләр | 1 11 07000 00 0000 120 | 73 975,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган чаралар | 1 11 08000 00 0000 120 | 2 700,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 00000 00 0000 000 | 329 434,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 12 01000 01 0000 120 | 307 600,0 |
| Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 02000 00 0000 120 | 16 843,0 |
| Урманнардан файдаланган өчен түләү | 1 12 04000 00 0000 120 | 4 991,0 |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 00000 00 0000 000 | 278 706,1 |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) керемнәр | 1 13 01000 00 0000 130 | 107 078,1 |
| Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 02000 00 0000 130 | 171 628,0 |
| Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 1 14 00000 00 0000 000 | 112 000,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр | 1 14 02000 00 0000 000 | 50 000,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен (бюджет һәм автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләреннән тыш) сатудан керемнәр | 1 14 06000 00 0000 430 | 62 000,0 |

| | | |
|---|---|---|
